ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май, 2021 ел № 7/6

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декабрендәге 4/7 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 9 статьяда**:

- **43 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

43) «федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»;

- түбәндәге эчтәлекле **44 пункт** өстәргә:

«44) шәһәр округы территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында мәгълүматларны күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү.»;

2) **9.1 статьяның 1 өлешенә** түбәндәге эчтәлекле **20 пункт** өстәргә:

«20) алкогольле, наркотик яки башка агулы матдәләр белән исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру;»;

3) **41 статьяда:**

**- 4 өлештә:**

**28 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»;

түбәндәге эчтәлекле **29 пункт** өстәргә:

«29) шәһәр округы территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, әлеге күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында мәгълүматларны күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү.»;

**12 өлешкә** түбәндәге эчтәлекле **10 пункт өстәргә**:

«10) алкогольле, наркотик яки башка агулы матдәләр белән исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;»;

- **15 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Физкультура һәм спортны үстерү өлкәсендә:

1) җирле шартлар һәм мөмкинлекләрне исәпкә алып, физик культура һәм спортны үстерүнең төп бурычларын һәм юнәлешләрен билгеләү, физик культура һәм спортны үстерү буенча муниципаль программаларны кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

2) шәһәр территориясендә массакүләм спортны, балалар-яшүсмерләр спортын һәм мәктәп спортын үстерү;

3) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 22 статьясы нигезендә спорт разрядлары һәм спорт судьяларының квалификация категорияләре бирү;

4) халыкның төрле төркемнәре, шул исәптән инвалидлар, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында физик культура һәм спортны популярлаштыру;

5) инвалидлар, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруны да кертеп, гражданнарның яшәү урыны һәм ял урыны буенча физкультура-спорт эшен оештыру, шулай ук муниципаль рәсми физкультура чаралары һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру, шул исәптән:

а) ГТО комплексын тормышка ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алган шәһәрнең физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарын раслау һәм тормышка ашыру;

б) шәһәрнең рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын медицина белән тәэмин итүне оештыру;

6) үз вәкаләтләре кысаларында шәһәр территориясендә рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә булышлык күрсәтү;

7) шәһәрнең спорт җыелма командаларын әзерләү өчен шартлар тудыру, шәһәрнең спорт җыелма командалары формалашырга мөмкин булган спорт төрләрен билгеләү, мондый командаларны формалаштыру һәм тәэмин итү тәртибен раслау, аларны муниципальара һәм региональ спорт ярышларында катнашу өчен җибәрү;

8) шәһәр тарафыннан тупланган һәм спорт әзерлеге федераль стандартлары нигезендә эшләнгән, спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар һәм (яки) физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итүне кертеп, шәһәр һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне тәэмин итүдә катнашу, шәһәр тарафыннан булдырылган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә спорт әзерлеге федераль стандартлары нигезендә эшләнгән спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

9) коммерцияле булмаган оешмаларга ГТО комплексы сынаулары нормативларын (тестларын) үтәүне бәяләү хокукы бирү;

10) Россия Федерациясе законнары һәм шәһәр Уставы нигезендә билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге Карар, үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган аерым нигезләмәләрдән тыш, матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2021 елның 2 июнендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002021002